Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Советы

**КАРАР №2-1**

Бәтке авылы 2020 елның 5 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Бәтке авыл
җирлеге Советының 2014 елның 14
октябрендәге 11 номерлы “Җир салымы
турында” карарына үзгәрешләр кертү турында»

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, 2019 елның 29 сентябрендәге “Россия Федерацисе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында” 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Уставына таянып,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсемуниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Советының “Җир салымы турында” карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Советының (2014 елның 14 ноябрендәге 12 номерлы, 2015 елның 25 маендагы 12 номерлы, 2017 елның 22 августындагы 9-1 номерлы, 2019 елның 13 июнендәге 5-1 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән)түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары билгән (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән гайре)яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуальторак төзелеше өчен сатып

алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән гайре)җир кишәрлекләренә карата -0,3%”

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авылы, Ленин урамы, 4 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Яншык авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 23 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Кече Укмас авылы, Гагарин урамы, 9Б йорт , адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәмТатарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсемуниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы Ф.М.Динмөхәмәтов